РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 200

2016 елның 22 августы

# Түбән Кама шәһәрендә 2016-2017 еллар җылылык бирү чорына әзерлекне тикшерү программасын раслау турында

Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2013 елның 12 мартындагы 103 номерлы боерыгы белән расланган җылылык бирү чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләренең 5 пункты нигезендә, шулай ук торак-коммуналь хуҗалык объектларын, җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре предприятиеләрен 2016-2017 еллар җылылык бирү чорында тотрыклы һәм ышанычлы эшләүгә үз вакытында әзерләү максатларында, карар бирәм:

1. Түбән Кама шәһәре предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләрен 2016-2017 еллар җылылык бирү чорына әзерләү буенча комиссия төзергә.

2. Түбән Кама шәһәре предприятиеләрен, оешмаларын һәм учреждениеләрен, җаваплы затлар белән килештереп, 2016-2017 еллар җылылык бирү чорына әзерләү комиссиясе составын расларга (1 нче кушымта).

3. Түбән Кама шәһәрендә 2016-2017 еллар җылылык бирү чорына әзерлекне тикшерү программасын расларга (2 нче кушымта).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Д.А. Филиппов

Түбән Кама шәһәре
башкарма комитетының
2016 елның 22 августындагы
200 номерлы карары белән расланган
1 нче кушымта

Түбән Кама шәһәре предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләрен
2016-2017 еллар җылылык бирү чорына әзерләү буенча комиссия составы

| | | |
|---|---|---|
| Филиппов Дмитрий Анатольевич | - | Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Мөбарәкшин Илшат Альберт улы | - | «Түбән Кама шәһәренең төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү департаменты» МУП директоры, комиссия рәисе урынбасары. |

Комиссия әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Вафин Рәдиф Шәүкәт улы | - | Ростехнадзорның Идел буе идарәсе Түбән Кама территориаль бүлегенең электр энергиясе җайланмаларына күзәтчелек буенча дәүләт инспекторы (килешү буенча); |
| Гәрәев Айдар Фердинант улы | - | «Генерирующая компания» ААҖ филиалы «Түбән Кама җылылык челтәрләре» директоры (килешү буенча); |
| Ихсанова Наилә Нариман улы | - | Түбән Кама зона торак инспекциясе башлыгы (килешү буенча); |
| Кондратьев Егор Владимирович | - | Ростехнадзор Идел буе идарәсе Түбән Кама территориаль бүлегенең казаннар күзәтчелеге һәм күтәрү корылмалары буенча дәүләт инспекторы (килешү буенча); |
| Красильников Василий Борисович | - | «Татэнергосбыт» ААҖ филиалының Кама бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Нуртдинов Илдар Наил улы | - | «Сүүткәргеч-канализация һәм энергетика хуҗалыгы» АҖ генераль директоры (килешү буенча); |
| Павлов Виталий Александрович | - | Ростехнадзор Идел буе идарәсе Түбән Кама территориаль бүлегенең җылылык энергиясе җайланмаларына күзәтчелек буенча дәүләт инспекторы (килешү буенча); |
| Салаватов Айрат Ринат улы | - | Ростехнадзорның Идел буе идарәсе Түбән Кама территориаль бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Слободюк Константин Петрович | - | Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча); |
| Төхвәтуллин Айрат Сәгыйть улы | - | Ростехнадзорның Идел буе идарәсе Түбән Кама территориаль бүлегенең газ күзәтчелеге буенча дәүләт инспекторы (килешү буенча). |

Түбән Кама шәһәре
башкарма комитетының
2016 елның 22 августындагы
200 номерлы карары белән расланган
2 нче кушымта

Түбән Кама шәһәрендә 2016-2017 елларда җылылык бирү чорына
әзерлекне тикшерү программасы

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Торак-коммуналь хуҗалык объектларының ышанычлылыгын тәэмин итү, кулланучыларны тотрыклы җылылык, су, электр, газ һәм ягулык белән тәэмин итү, энергия үткәргечләрнең кирәкле параметрларын тоту һәм, аларның билгеләнешен һәм торак-коммуналь хезмәтләрне кулланучыларның түләү дисциплинасын исәпкә алып, биналарда норматив температура режимын тәэмин итү максатларында, җылылык бирү чорына үз вакытында һәм һәрьяклап әзерләнү һәм аны оештырылган төстә уздыру җирле үзидарә органнарының, торак-коммуналь хуҗалык оешмаларының мөһим бурычы булып тора.

Торак-коммуналь хуҗалык объектларын җылылык бирү чорына әзерләү температураның һәм башка һава шартларының аларның эшләү ышанычлылыгына йогынтысын булдырмау, нормадан тыш тузуны һәм сафтан чыгуны кисәтү, шулай ук таләп ителә торган халыкның тормыш эшчәнлеге шартларын һәм коммуналь инфраструктура һәм җылылык бирү чорында биналарны инженер-техник тәэмин итү системаларының эшләү режимнарын тәэмин итү максатыннан үткәрелә.

Торак-коммуналь хуҗалык объектларын җылылык бирү чорына әзерләү түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

- торак-коммуналь хуҗалык объектларын норматив-техник эксплуатацияләү, биналарда билгеләнгән температура-дымлылык режимын үтәү, халыкның яшәү шартларының санитар-гигиена шартларын үтәү;
- торак-коммуналь хуҗалык объектлары эшенең максималь ышанычлылыгы һәм экономияле булуы;
- торак фонды һәм социаль өлкә биналарының, коммуналь корылмалар җиһазларының төзелеш конструкцияләре һәм инженер-техник тәэмин итү системалары хезмәт итүенең норматив срокларын үтәү;
- матди-техник чараларны һәм ягулык-энергетика ресурсларын рациональ тоту.

Торак-коммуналь хуҗалык объектларын җылылык бирү чорына вакытында һәм сыйфатлы итеп әзерләү түбәндәге очракларда  ирешелә:

- вазыйфаи затлар тарафыннан федераль һәм өлкә законнары, муниципаль норматив хокукый актлар таләпләрен, торак-коммуналь хуҗалык объектларын эксплуатацияләү кагыйдәләрен,  кулланма һәм күрсәтмәләр таләпләрен үтәү;
- төзелешкә проект-смета документларын, капиталь һәм агымдагы ремонт планнарын, шулай ук торак-коммуналь хуҗалык объектларына техник хезмәт күрсәтү планнарын эшләү һәм үтәү;

- техник торышны, планлы-кисәтү тикшерүләренең барлык төрләрен тикшерүне даими контрольдә тоту, шулай ук аварияләр һәм төзексезлекләр килеп чыгу сәбәпләрен җентекләп анализлау һәм кирәкле ремонт-торгызу эшләренең күләмен билгеләү;

- ремонт-торгызу һәм көйләү эшләрен билгеләнгән вакытта һәм таләп ителгән сыйфат белән төгәл оештыру һәм башкару, бурычлар куюның һәм ремонт-торгызу эшләренә йомгак ясауның нәтиҗәле системасын куллану;

- торак-коммуналь хуҗалык оешмаларын эксплуатация һәм эксплуатация-ремонт персоналы белән йөкләнә торган бурычларны хәл итүне тәэмин итә торган дәрәҗәгә кадәр комплектлау;

- ремонт-торгызу эшләрен матди-техник тәэмин итү, эксплуатация кирәк-яракларына кирәкле максатчан финанслау бүлеп бирү, фондны капиталь һәм агымдагы ремонтлау, матди ресурслардан рациональ файдалану;

- җылылык бирү чоры башланыр алдыннан, оештыру-техник чараларны, җиһазларның эшләвен тикшерү һәм сынау комплексын тулысынча үтәү.

## 2. Җылылык бирү чорына әзерлекне тикшерү буенча комиссия эше

2.1. Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты түбәндәгеләрне оештыра:

- җылылык белән тәэмин итү чыганакларының, үзәк җылылык пунктларының, муниципаль берәмлекләрнең җылылык челтәрләренең һәм гомумән җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның җылылык бирү чорына әзерлеген тикшерү буенча комиссия эшен;

- торак-коммуналь хуҗалык һәм социаль өлкә объектларының җылылык бирү чорына әзерлеген тикшерү буенча комиссия эшен;

- торак фондының җылылык кабул итүгә, коммуналь корылмаларның җылылык бирү чорына әзерлеген тикшерүне, коммуналь объектларның һәм авария бригадаларының дежур сменалары әзерләнгән һәм аттестацияләнгән персонал белән комплектлануы, аларны авария хәлендәге кимеми торган ТМС, ягулык һәм химик реагентлар запасы белән тәэмин итү.

Җылылык белән тәэмин итү чыганакларының, үзәк җылылык пунктларының, муниципаль берәмлекләрнең җылылык челтәрләренең һәм гомумән җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның җылылык бирү чорына әзерлеген бәяләү Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган комиссия тарафыннан 15 сентябрьдән дә соңга калмыйча билгеләнә.

Комиссия Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты карары белән раслана.

Комиссия эше җылылык бирү чорына әзерлекне тикшерү графигына туры китереп башкарыла (1 нче таблица), анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

- тикшерелергә тиешле объектлар;
- тикшерү үткәрү срогы;
- тикшерү барышында тикшерелә торган документлар.

1 нче таблица

Җылылык чорына әзерлекне тикшерү графигы

| Тәртип № | Тикшерелергә | Объектлар | Тикшерү | Тикшерү |
|---|---|---|---|---|

| | тиешле объектлар | саны | үткәрү сроклары | барышында тикшерелә торган документлар |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Җылылык челтәрләре оешмалары:<br><br>а) «Сууткәргеч-канализация һәм энергетика хуҗалыгы» АҖ<br><br>б) «Генерирующая компания» ААҖ филиалы «Түбән Кама җылылык челтәрләре» | 2 | 01.06.2016-01.09.2016 | 3нче кушымта нигезендә |
| 2 | Түбән Кама шәһәре торак фонды | 795 | 01.06.2016-01.09.2016 | 4нче кушымта нигезендә |
| 3 | Шул исәптән: күпфатирлы йорт-лар | 779 | | |
| 4 | ведомство торагы | 16 | | |
| 5 | Түбән Кама шәһәре социаль өлкәләре объ-ектлары | 224 | | |

Тикшерү барышында комиссия тарафыннан Түбән Кама шәһәрендә 2016-2017 елларда җылылык бирү чорына әзерлекне тикшерү буенча әлеге программаның 3, 4 нче кушымталарында билгеләнгән таләпләрнең үтәлеше тикшерелә (алга таба – Программа).

Җылылык челтәрләре һәм җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2013 елның 12 мартындагы 103 номерлы боерыгы (алга таба – кагыйдәләр) белән расланган җылылык бирү чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләре белән билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тикшерү җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә техник регламентларда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тиешле мәҗбүри таләпләрне үтәү предметына комиссия тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Кагыйдәләрдә билгеләнгән таләпләргә карата җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә техник регламентларның яисә башка норматив-хокукый актларның

мәҗбүри таләпләре булмаган очракта, комиссия җылылык бирү чорына әзерлек тәртибен җайга салучы тикшерелергә тиешле оешмаларның локаль актлары үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

2.2. Тикшерү үткәрү максатларында, комиссия әзерлек буенча таләпләрнең үтәлешен раслаучы документларны карый, ә кирәк булганда – тикшерү объектларын карый.

Тикшерү нәтиҗәләре, әлеге Кагыйдәләргә 1 нче кушымта нигезендә, тәкъдим ителгән үрнәк буенча, тикшерү тәмамланганнан соң бер көннән дә соңга калмыйча төзелә торган җылылык бирү чорына әзерлекне тикшерү акты (алга таба – акт) белән рәсмиләштерелә.

Актта тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссиянең түбәндәге нәтиҗәләре күрсәтелә:

- тикшерү объекты җылылык бирү чорына әзер;

- тикшерү объекты, билгеләнгән срокта комиссия тарафыннан бирелгән әзерлек таләпләренә карата кисәтүләрне бетерү шарты белән, җылылык бирү чорына әзер булачак;

- тикшерү объекты җылылык бирү чорына әзер түгел.

Комиссиянең әзерлек таләпләрен үтәүгә карата шелтәләре булса яки әзерлек таләпләрен үтәмәгән очракта, актка, аларны бетерү срокларын күрсәтеп, кисәтүләр исемлеге (алга таба – Исемлек) теркәлә.

Җылылык бирү чорына әзерлек паспорты (алга таба - паспорт) тәкъдим ителә торган үрнәк буенча әлеге Программага 2 нче кушымта нигезендә төзелә һәм һәр тикшерү объекты буенча, актка кул куелганнан соң 15 көн эчендә, әгәр дә тикшерү объекты җылылык бирү чорына әзер булган очракта, шулай ук комиссия тарафыннан бирелгән әзерлек буенча таләпләргә кисәтүләр Исемлектә билгеләнгән срокта бетерелгән очракта, комиссия тарафыннан төзелә.

Паспортларны бирү сроклары, климат шартлары үзенчәлекләренә карап, комиссия рәисе (рәис урынбасары) тарафыннан билгеләнә, әмма 15 сентябрьдән дә соңга калмыйча – җылылык энергиясен кулланучылар өчен, 1 ноябрьдән дә соңга калмыйча – җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмалары өчен, 15 ноябрьдән дә соңга калмыйча – муниципаль берәмлекләр өчен.

Әлеге Программага 1 нче таблицада билгеләнгән срокларда әзерлек таләпләрен үтәү (үтәмәү) буенча Исемлектә күрсәтелгән кисәтүләрне бетергән очракта, комиссия кабат тикшерү үткәрә, аның нәтиҗәләре буенча яңа акт төзелә.

Әлеге Программага 1нче таблицада билгеләнгән датага кадәр тикшерү объектлары буенча әзерлек паспортын алмаган оешма җылылык бирү чорына әзерлекне һәм актка Исемлектә күрсәтелгән әзерлек буенча таләпләрне үтәүгә (үтәмәүгә) карата кисәтүләрне бетерүне дәвам итәргә тиеш. Комиссиягә әзерлек буенча таләпләрне үтәүгә (үтәлмәүгә) кисәтүләрне бетерү турында хәбәр иткәннән соң, кабат тикшерү башкарыла. Комиссиянең уңай бәяләмәсе алынганда, җылылык бирү чорына әзерлек турында нәтиҗә белән, әмма агымдагы җылылык бирү чорына паспорт бирмичә, кабат акт рәсмиләштерелә.

3. Җылылык кулланучы җайланмалары җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтырылган җылылык белән тәэмин итү һәм җылылык челтәрләре оешмаларының, җылылык энергиясен кулланучыларның комиссия белән үзара хезмәттәшлеге тәртибе

1. Җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмалары «Түбән Кама шәһәренең төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү департаменты» муниципаль унитар предприятиесенә (алга таба - ТКХ департаменты) 3 нче кушымтада күрсәтелгән әзерлек таләпләрен үтәү буенча мәгълүмат тапшыралар.

Комиссия Программаның 2.2 пункты нигезендә әзерлек таләпләрен үтәүне раслаучы документларны карый.

2. Җылылык энергиясен кулланучылар җылылык белән тәэмин итүче оешмага 4 нче кушымтаның 2, 5, 8 нче пунктларында күрсәтелгән әзерлек таләпләрен үтәү буенча мәгълүмат тапшыралар. 4 нче кушымтаның 1, 3, 4, 9 нчы пунктларында, өлешчә 10, 15, 17 нче пунктларында күрсәтелгән таләпләрне үтәү буенча мәгълүматны кулланучылар комиссия таләбе буенча мөстәкыйль рәвештә ТКХ департаментына карауга тапшыралар.

Җылылык белән тәэмин итүче оешма кулланучыларның җылылык энергиясен исәпкә алу төеннәрен эксплуатацияләүгә кертә, җылылык пунктлары җиһазларының тыгызлыгына һәм ныклыгына карата сынауларында, җылылык белән тәэмин итү системаларын гидропневматик юдыртуда катнаша һәм тикшерү объектларын карый.

Җылылык белән тәэмин итүче оешма кулланучыларның 2016/2017 еллар җылылык бирү чорына әзерлеген тикшерү актын рәсмиләштерә һәм аны ТКХ департаментына комиссия каравына җибәрә.

Атна саен һәр дүшәмбе җылылык белән тәэмин итүче оешма ТКХ департаментына кулланучылар объектларын җылылык бирү чорына әзерләү турында белешмә рәвешендә мәгълүмат бирә.

Комиссия Программаның 2.2 пункты нигезендә әзерлек таләпләрен үтәүне раслаучы документларны карый.

1 нче кушымта

2016/2017 еллар җылылык бирү чорына әзерлекне тикшерү
____ номерлы акты

___________________________ «_____»____________ 20__ ел.
(актны төзү урыны) (актны төзү датасы)

_____________________________________________________ ___төзелгән комиссия
(комиссия төзелгән документ формасы һәм аның реквизитлары)
«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «___»____________20__ елдан алып «___»_____________ 20__ елга кадәр чорга
__________________________________________________________________________
(җылылык бирү чорына әзерлекне тикшерүче орган җитәкчесенең (аның урынбасарының) ФИА (ис.))
тарафыннан расланган «___»_____________20__ елдан җылылык бирү чорына әзерлекне тикшерү программасы нигезендә, җылылык белән тәэмин итү чорына әзерлекне тикшерде
__________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________
(аңа карата җылылык бирү чорына әзерлекне тикшерү үткәрелгән муниципаль берәмлекнең, җылылык белән тәэмин итүче оешманың, җылылык челтәре оешмасының, җылылык энергиясен кулланучының тулы исеме)

Җылылык бирү чорына әзерлек түбәндәге объектларга карата тикшерелде:
1.________________________________________________________;
(объектның исеме, мәйданы - мең кв.м)
2.________________________________________________________;
(объектның исеме, мәйданы - мең кв. м)
3.________________________________________________________;
(объектның исеме, мәйданы - мең кв. м)
Җылылык бирү чорына әзерлекне тикшерү барышында комиссия билгеләде: _________________________________________________________________.
(җылылык бирү чорында эшләргә әзер булу/әзер булмау.
Җылылык бирү чорына әзерлекне тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия бәяләмәсе:__________________________________________________________
__________________________________________________________________________
Җылылык чорына әзерлекне тикшерү актына кушымта __/__ еллар.*

Комиссия рәисе: ____________________/________________
(имза, имзаны расшифровкалау)
Комиссия рәисе урынбасары:____________________/________________
(имза, имзаны расшифровкалау)
Комиссия әгъзалары: ____________________/________________
(имза, имзаны расшифровкалау)
____________________/________________
(имза, имзаны расшифровкалау)
____________________/________________
(имза, имзаны расшифровкалау)

______________________/_________________
(имза, имзаны расшифровкалау)
______________________/_________________
(имза, имзаны расшифровкалау)

Әзерлекне тикшерү акты белән таныштым, актның бер нөсхәсен алдым:
«___»____________20__ел.___________________________________________
(аңа карата җылылык бирү чорына әзерлекне тикшерү үткәрелгән җылылык энергиясен кулланучы муниципаль берәмлек, җылылык белән тәэмин итүче оешма, җылылык челтәрләре оешмасы җитәкчесенең (аның вәкаләтле вәкиленең) имзасы, имзаны расшифровкалау)

20__ елның «_____»_______________ ____ номерлы
җылылык бирү чорына әзерлекне тикшерү актына
әзерлек буенча таләпләрне үтәүгә яки
әзерлек буенча таләпләрне үтәмәүгә кисәтүләр исемлеге

1.______________________________________________________________________
________________________________________________________________________

Бетерү срогы -______________________
(дата)

2.______________________________________________________________________
________________________________________________________________________

Бетерү срогы -______________________
(дата)

3.______________________________________________________________________
________________________________________________________________________

Бетерү срогы -______________________
(дата)

2 нче кушымта

_______/______ еллар җылылык бирү чорына әзерлек паспорты

_____________________________________________________________тарафыннан бирелгән
(аңа карата җылылык бирү чорына әзерлекне тикшерү үткәрелгән җылылык энергиясен кулланучы муниципаль берәмлек, җылылык белән тәэмин итүче оешма, җылылык челтәрләре оешмасының тулы исеме)

Җылылык бирү чорына әзерлек түбәндәге объектларга карата тикшерелде
1._________________________;
2._________________________;
3._________________________;

Җылылык бирү чорына әзерлек паспортын бирү нигезләре:
____________ _______ __номерлы җылылык бирү чорына әзерлекне тикшерү акты.

_________________________/__________________________
(җылылык чорына әзерлекне тикшерү буенча комиссияне төзегән вәкаләтле органның имзасы, имзаны расшифровкалау, мөһере)

3 нче кушымта

Җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәре оешмалары өчен җылылык бирү чорына әзерлек таләпләре

Җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмаларының җылылык бирү чорына әзерлеген бәяләү максатларында, вәкаләтле орган әлеге оешмаларга карата тикшерергә тиеш:

1) Җылылык белән тәэмин итү турында законда билгеләнгән тәртиптә төзелгән җылылык белән тәэмин итү системасы белән идарә итү турында килешү булу;

2) җылылык белән тәэмин итү схемасы белән расланган җылылык йөкләнеше графигын үтәүгә, температура графигын саклауга әзерлек;

3) җылылык белән тәэмин итүнең техник регламентларда билгеләнгән ышанычлылылык критерийларын үтәү;

4) җылылык энергиясе чыганакларында норматив ягулык запаслары булу;

5) эксплуатация, диспетчерлык һәм авария хезмәтләре булу, ә атап әйткәндә:

- күрсәтелгән хезмәтләрнең персонал белән комплектлануы;

- персоналны шәхси һәм коллектив саклау чаралары, махсус кием, инструментлар һәм җитештерү өчен кирәкле җиһазлар белән тәэмин итү;

- норматив-техник һәм оператив документлар, инструкцияләр, схемалар;

- беренчел янгын сүндерү чаралары;

6) алар карамагындагы җылылык челтәрләрен җайга салу;

7) җылылык энергиясен куллану режимнарын контрольдә тотуны оештыру;

8) җылылык китерүчеләрнең сыйфатын тәэмин итү;

9) сатып алына торган һәм сатыла торган җылылык энергиясенең коммерция исәбен оештыру;

10) җылылык челтәрләре төзелеше сыйфатын тикшерүне тәэмин итү, шул исәптән, җылылык белән тәэмин итү турында закон нигезендә, төзелештә кулланыла торган эшләр һәм материалларга гарантияләр бирү.;

6) проведение наладки принадлежащих им тепловых сетей;

11) җылылык белән тәэмин итү объектларының авариясез эшләвен һәм җылылык энергиясен кулланучыларны җылы белән тәэмин итү:

- ягулык кабул итү һәм бушату, ягулык әзерләү һәм ягулык бирү системаларының әзерлеге;

- су-химия режимын үтәү;

- җылылык-энергетика җиһазларын эксплуатацияләү вакытын озайту буенча тиешле оештыру-техник чаралар үткәрмичә генә файдалану фактларының булмавы;

- җылылык чыганакларының җылылык егәрлегенә кытлык булганда җылылык белән тәэмин итүне һәм җылылык челтәрләренең үткәрүчәнлек сәләтен чикләүнең расланган графиклары булу;

- торак йортларны җылылык белән тәэмин итү буенча авария хәлендәге җитешсезлекләрне бетерүнең рөхсәт ителгән вакытының исәп-хисаплары булу;

- җылылык, электр, ягулык һәм су белән тәэмин итү оешмаларының, җылылык энергиясен кулланучыларның, ремонт-төзелеш һәм транспорт оешмаларының,

шулай ук җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеген исәпкә алып, җылылык белән тәэмин итү системаларында авария хәлләрен бетерү тәртибенең булуы;

- җылылык челтәрләренең гидравлик һәм җылылык сынаулары үткәрү;

- җылылык белән тәэмин итүдә катнашучы җиһазларны тиешле техник тикшерү һәм диагностикалау үткәрү кертелгән җылылык бирү чорына эшкә әзерлекнең расланган планын үтәү;

- җылылык челтәрләрен һәм җылылык энергиясе чыганакларын ремонтлау буенча планлы графигын үтәү;

- ягулык белән тәэмин итү һәм ягулык запасларының билгеләнгән нормативларын киметүгә юл куймый торган ягулык белән тәэмин итү шартнамәсе булуы;

12) җылылык энергиясен кулланучылар, җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмалары арасында эксплуатация җаваплылыгын чикләүне билгели торган документлар булу;

13) дәүләт хакимияте органнары тарафыннан дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтлеләр биргән җылылык бирү чорында эшнең ышанычлылыгына йогынты ясый торган билгеләнгән срокларда үтәлмәгән кисәтмәләрнең булмавы;

14) автоматик регуляторлар булганда, аларның эшләве.

Катнаш эшләп чыгару режимында җылылык һәм электр энергиясе җитештерү объектларына карата электр энергетикасы турында закон нигезендә алынган җылылык бирү сезонына әзерлек турында документның булуы гына тикшерелә.

Җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмаларына карата, кисәтүләрне бетерү срокларын күрсәтеп, исемлекне кушып акт төзелә торган хәлләргә әлеге 3 нче кушымтаның 1, 7, 9 һәм 10 пунктчаларында күрсәтелгән таләпләрне үтәмәү керә.

4 нче кушымта

Җылылык энергиясен кулланучылар өчен
җылылык бирү чорына әзерлек буенча таләпләр

Җылылык энергиясен кулланучыларның җылылык бирү чорына әзерлеген бәяләү максатларында, вәкаләтле орган тарафыннан тикшерелергә тиеш:

1) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә җылылык энергиясе җайланмаларының җылылык һәм гидравлик эш режимнарында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү;

2) җылылык кулланучы җайланмаларның җиһазларын һәм коммуникацияләрен юдыру;

3) эксплуатация режимнарын, шулай ук аларны гамәлгә кертү чараларын эшләү;

4) ремонт эшләре планын үтәү һәм аларны үтәү сыйфаты;

5) җылылык энергиясен кулланучыга караган җылылык челтәрләренең торышы;

6) биналарның (чардаклар, баскыч мәйданчыгы, подваллар, ишекләр) һәм үзәк җылылык пунктларының, шулай ук индивидуаль җылылык пунктларының җылыту торышы;

7) җылылык пунктлары чикләрендә торба үткәргечләрнең, арматура һәм җылылык изоляциясенең торышы;

8) исәпкә алу приборларының булу һәм эшкә ярашлыгы, алар булганда автомат җайга салучыларның эшкә ярашлыгы;

9) җылылык куллану системаларын саклауның эшкә ярашлыгы;

10) җылылык кулланучы җайланмаларның паспортлары, хезмәт күрсәтүче персонал өчен принципиаль схемалар һәм инструкцияләр булу һәм аларның чынбарлыкка туры килүе;

11) суүткәргеч һәм канализация белән җылылык пунктлары җиһазларының турыдан-туры тоташтырылмалары булмау;

12) җылылык пунктлары җиһазларының тыгызлыгы;

13) исәп-хисап алкаларында һәм элеватор соплоларында пломбалар булу;

14) тапшырылган җылылык энергиясе (егәрлек), җылылык китерүче өчен бурычлар булмау;

15) үз һәм (яки) җәлеп ителгән ремонт бригадаларының булуы һәм җылылык куллану җайланмаларыннан тиешенчә файдалану өчен аларның матди-техник ресурслары белән тәэмин ителеше;

16) җылылык кулланучы җайланмаларның тыгызлыгына һәм ныклыгына сынау үткәрү;

17) РФ Энергетика министрлыгының «Җылылык бирү чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 12 мартындагы 103 номерлы боерыгының 3 нче кушымтасында китерелгән критерийлар нигезендә, климат шартларын исәпкә алып, җылылык энергиясен кулланучыларны җылылык белән тәэмин итүнең ышанычлылыгы.

Аларны үтәмәгәндә, җылылык белән тәэмин итүчеләргә карата, кисәтүләрне бетерү срокларын күрсәтеп, исемлекне кушып акт төзелә торган хәлләргә әлеге 4 нче кушымтаның 8, 13, 14 һәм 17 пунктчаларында күрсәтелгән таләпләрне үтәмәү керә.